**Республика Татарстан**
**Карашай-Сакловское сельское поселение Сармановского муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районының Карашай-Саклау авыл җирлеге**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

05 ноябрь 2020 ел — № 3

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Карашай-Саклау авыл
җирлеге Чураш авылында
гражданнарның үзара салым
акчаларын кертү һәм алардан
файдалану мәсьәләсе буенча
халык җыенын билгеләү
турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, 18.1 статьясы нигезендә. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлеге Уставы:

1.Чураш авылы мәдәният йорты бинасында,  гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның 16 нояберенә 11 сәгать 00 минутта билгеләргә

2.Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлеге территориясендә җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:«I группа инвалидлар, көндезге бүлек студентлары, хәрби хезмәт узучы хезмәткәрләрдән тыш, Карашай-Саклау авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ кешедән, 2021 елда 500  сум үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне башкаруга тоту белән килешәсезме:

- Чураш авылызиратына баруча юлны хэм Комсомол урамы юлын ремонтлау вак таш жэю ( вак таш таш ташу);

- Чураш авылы зиратына триммер алу;

- Чураш авылларында урам яктырткычларын ремонтлау һәм урнаштыру;;

-Чураш авылында урнашкан памятникны ремонтлау(брусчатка жэю )

-сабантуй уткэрэ торган урынга урам туалеты алу;

-кыш көне Чураш авылларындагы юлларны кардан чистарту;

- район газетасында некрологларны бастырып чыгару;

«ӘЙЕ» «ЮК?».

3.Карашай Саклау авыл җирлеге Башкарма Комитетына халык җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

4Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында, Чураш авылы торак пунктлары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

5. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Карашай-Саклау Советы Башлыгы

авыл җирлеге Башлыгы В. В. Хөсниева